Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Казаклар авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«08» ноябрь, 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Казаклар авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Казаклар авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:
- Нурми Шәрипов урамындагы су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, торбалар урнаштыру, махсус техника хезмәтләре күрсәтү);

2. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә

3. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Казаклар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Казаклар авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (ukay.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http//pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Теләнче Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Нәҗметдинов